# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге составына керүче Омар торак пунктында 2023 елга үзарасалымкертү турында

№ 8 28 октябрь 2022 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нчыстатьялары, «Татарстан Республикасындаҗирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нчестатьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлегенең Омар торак пунктында узган гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Омар авыл җирлеге Омар торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, БөекВатансугышы катнашкан ветераннар, БөекВатансугышында катнашканнарның тол хатыннары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2023 елда алты йөз сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирлеә һәм иять тәгемәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башка ругатотарга:

- Омар торак пунктында Приречная урамына, Заключье урамына вак таш җәю (сатып алу, ташу,ком, вак таш җәю, кырдырып тигезләү, килешү буенча эш өчен түләү);
- Омар торак пунктында юлларны кардан чистарту;
- Омар торак пунктында урам яктырту объектларына хезмәт күрсәтү (агымдагы ремонт, махсус җиһазлар сатып алу һәм алыштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү);

3.Әлеге карарны Омар авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Омар авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе Л.Н.Хәбибуллин